РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА АЗНАКАЕВО АЗНАКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул. Ленина, д.14, г. Азнакаево, 423330

Ленин ур.,14 нче йорт, Азнакай ш., 423330

Тел./факс(885592)7-15-50,7-00-37; E-mail:aznakay@tatar.ru, adm-aznakay@mail.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.01.2020 ел № 03

2020 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районыны «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге хакының чик күләмен раслау турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы «Җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 ел, 18 май, 196 нчы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020т елның 29 гыйнварындагы 61 нче номерлы «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» карары нигезендә, карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә 2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә 6124,86 (алты мең йөз егерме дүрт сум, 86 тиен) күләмендә бәянең чик күләмен, 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә, билгеләргә.

2. Азнакай шәһәре Башкарма комитетының 2009 елның 12 апрелендәге 12 нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http// pravo. tatarstan. ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo. tatarstan. ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче М.И.Солтанов

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымта
«____» _________2020 № _______

2020 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча бәянең чик күләме

| № | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүнең хакы, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4148,86 |
| 2 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 863,00 |
| 3 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1113,00 |
| **4** | **Барлыгы** | **6124,86** |

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Башкарма
комитеты карарына 2 нче кушымта
«____» _________2020 № _______

2020 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча бәянең чик күләме

| № | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүнең хакы, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Кәфенләү | 841,42 |
| 2 | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3307,00 |
| 3 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 863,44 |
| 4 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1113,00 |
| **5** | **Барлыгы** | **6124,86** |